| | |
|---|---|
| ГЛАВА РАНГАЗАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РАНГАЗАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 ел, 2 ноябрь Рангазар авылы № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рангазар авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Рангазар авылы гражданнары җыенын Рангазар авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Рангазар авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Рангазар авылларында урамнарны яктырту, яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;
- Беларус-320.4 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Рангазар авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Рангазар авылларында чаралар (Җиңү көне, Сабантуй, Өлкәннәр көне) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
-Рангазар авыл зиаратында биек агачларны кисүгә( килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылында коры агачлар ,куакларны кисүгә (килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылының киров урамына шлагбаум үзерләү һәм урнаштыру өчен.

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Рангазар авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Рангазар авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Рангазар авыл җирлеге башлыгы: А.Р.Шарипова.